| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.02.2022 Мөрәле ав. № 26

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 октябрендәге 15 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы « Мөрәле авыл җирлеге» Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр проектын кабул итәргә (1нче кушымта)

2. Расларга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының « Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының « Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Мөрәле авыл җирлеге Советы депутаты Мифтахова Рәзилә Ринат кызы, Мөрәле авыл җирлеге Советы депутаты Садриева Алсу Зөлфикәр кызы, Мөрәле авыл

җирлеге Советы депутаты Билалиев Альберт Рифкат улы.

4. Гавами тыңлауларны 2022 елның 04 мартында 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Мөрәле авылы,Үзәк урам,45 нче йорт адресы буенча урнашкан Мөрәле авылы мәдәният йорты бинасында уздырырга.

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Советы депутатлары һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының « Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Советына карауга чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының « Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең http://muralin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы — Зиннәтуллин Р.Р.